СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫНЫ

ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫН ИЖТИМАГЫЙ СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 6 июленнән бирлә чыга. | №100 (7273) | 20 август, 1991 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

Бүген район укытучыларының август киңәшмәсе башланды. Фәннәр һәм тәрбия эше буенча секция утырышлары шәһәр мәктәпләрендә оештырыла. Ә иртәгә киңәшмәнең пленар утырышы район культура йортында үткәреләчәк.

Мәгариф работниклары өчен киеренке хезмәт елы башлана. Аларга изге эшләрендә уңышлар телик!

ТАСС белдерүе

Мәгълүм булганча, 1991 елның 19 августыннан илдә гадәттән тыш хәл кертелде. Ил белән идарә итү һәм гадәттән тыш хәлне нәтиҗәле гамәлгә ашыру режимы булдыру максатларында, СССРда гадәттән тыш хәл буенча Дәүләт комитеты (СССР ГКЧПсы) оештырылды. СССР ГКЧПсының Карары ССР Союзының барлык территориясендә барлык власть һәм идарә органнары, вазифалы кешеләр һәм барлык гражданнарга тайпылышсыз үтәү өчен мәҗбүри. СССР вице-президентының 1991 ел 18 август Указы нигезендә, сәламәтлегенең торышы буенча М. С. Горбачевның СССР Президенты вазифаларын үти алу мөмкинлеге булмавын исәпкә алып, СССР Конституциясенең 127(7) статьясы нигезендә, СССР вице-президенты Г.И. Янаев 1991 елның 19 августыннан СССР Президенты вазифаларын башкарырга керешә.

Гадәттән тыш хәл буенча Дәүләт Комитеты совет халкына Мөрәҗәгать белән чыгыш ясады. Анда, аерым алганда, М. С. Горбачев инициативасы белән башланган, илнең динамик үсешен тәэмин итү һәм җәмгыять тормышын демократияләштерү чарасы буларак күздә тотылган реформалар политикасы байтак сәбәпләр аркасында тупикка килеп төртелүе билгеләнә: ил, чынбарлыкта, идарә ителми башлады. СССРда гадәттән тыш хәл буенча Дәүләт Комитеты кризисның тирәнлеге турында үзенә тулысы белән отчет бирә, ул Ватан язмышы өчен җаваплылыкны үз өстенә ала һәм дәүләтне кризис хәленнән чыгару буенча иң җитди чаралар күрергә әзер булуын белдерә.

СССР ГКЧПсы үзенең эшләре белән яңа Союз договоры проектын киң тәртиптә бөтенхалык тикшерүен тәэмин итә, законлылыкны һәм хокук тәртибен кичектергесез торгызуны, илне яңарышка алып баручы әзлекле реформалар политикасын гамәлгә ашыруны, барлык гражданнарның тормыш хәлен даими яхшырта баруны алга куя, дип басым ясала Мөрәҗәгатьтә.

Совет җитәкчелеге тапшыруы буенча СССР Президенты вазифаларын башкаручы Г. И. Янаев дәүләтләр һәм хөкүмәтләр башлыкларына һәм БМОның Генеральный секретарена СССРның аерым урыннарында 6 айлык срок белән гадәттән тыш хәл кертелүе һәм илдә власть бөтен тулылыгы белән СССРда гадәттән тыш хәл буенча Дәүләт Комитеты кулына тапшырылуы турында хәбәр итте.

СССР Югары Советы Рәисе А. И. Лукьянов белдерү белән чыкты, анда ул нигез хокуклы суверен республикаларның яңартылган федерациясе буларак Совет Социалистик Республикалар Союзын саклау буенча Югары Советның позициясе Союз Договорының йомгаклау текстында чагылыш тапмавын билгеләп узды. Югары Совет Рәисе фикере буенча бу мәсьәлә СССР халык депутатлары съездында өстәмә рәвештә тикшерүне, мөгаен, яңа Конституция кабул итүгә бәйле рәвештә Бөтенсоюз референдумы юлы белән хәл итүне таләп итә. (ТАСС).

ТАНЫШ БУЛЫГЫЗ: рәсемдә Якушкино урта мәктәбе директоры Ю. Н. Евдокимова.

Рәсемнән үк күренгәнчә, Юлия Николаевна тормышны яратучы, шат күңелле, җитез кеше. Ә мәктәп директоры өчен әлеге сыйфатлар икенчел нәрсә түгел. Хәер, Якушкино мәктәбе җитәкчесенең килмәгән бер генә җире дә юк: алда санап үтелгән сыйфатлары өстенә әле ул бер дигән педагог, яхшы остаз да. Химия-биология фәне буенча балалар ныклы белем алалар, берничә дистә төр яшелчә, җиләк-җимеш үстерелә торган мәктәп яны участогында хезмәткә өйрәнеп үсәләр икән, монда да Юлия Николаевнаның өлеше зур. Гомумән, якушкинолылар җитәкчеләреннән уңдылар. Бу—коллективта яхшы микроклимат, үзара аңлашып, бер максатка тупланып эшләү дигән сүз.

ХУПЛЫЙМ

Бүгенге гадәттән тыш хәл күптән көтелгән иде. Илнең таркалуын тыныч кына карап тору мөмкин түгел. Болар бит барысы да бердәм, тотрыклы экономикасы, политикасы булмау нәтиҗәсе. Бөтенсоюз референдумы белән бердәм Союз дәүләтен саклау турында карар итсәк тә, аерым республикалар үзәкне игътибарга да алмыйча килешүләр төзүгә барып җиттеләр.

Халыкның өлкән буыннары—пенсионерлар, инвалидларның тормышы язмыш кулына тапшырылды. Эш хакы 600 әр сумга җитте, ә пенсиянең күләме 120 булып калды, 60 сум компенсация бирелде, ә әйберләрнең бәяләре 3—4 тапкыр артты. Шуңа күрә карт кешеләр бу үзгәрешне һәммәсе дә хуплап каршы алгандыр, дип уйлыйм.

Әлбәттә, М. С. Горбачевның ниятләре изге иде. Сталинизмны фаш итү, ул заманнардагы репрессияләнгән кешеләрне аклау, Әфганстан сугышын туктату һәм башкалар—аның хезмәте. Ләкин халык җитәкчелектә йомшаклык күрсәтүне кабул итә алмады.

И. ГЫЙЛӘҖЕВ,
Норлат шәһәре.

ӨМЕТ УЯНДЫ

Илдәге хәлне стабильләштерү, политик, милли һәм башка проблемаларны хәл итү максатында аерым регионнарда гадәттән тыш хәл кертү турындагы хәбәрне ишеткәч җиңел сулап куйдым. Үткәреләчәк чаралар илдә тәртип, җәмгыятьнең яңарыш чорында халык мәнфәгате өчен һәм экстремистик элементларга каршы көрәшергә мөмкинлек бирер дигән өмет туды.

Мондый хәлдә тынычлык саклау, аңлылык һәм җаваплылык белән эшләү зарури. Совет, партия, профсоюз органнарына бу көннәрдә массалар, хезмәт коллективлары арасында аерым эшләр алып бару буенча зур бурычлар йөкләнә дип уйлыйм.

А. ДМИТРИЕВ,
сугыш һәм хезмәт ветераны.

КӨТЕЛГӘН ҮЗГӘРЕШ

Бүгенге көн килүен шатланып каршы алдым һәм бөтен күңелем белән хуплыйм. Сәбәбен аңлатуы читен түгел, барысы да күз алдында бит: кибет киштәләре бушап калды, кайсы гына өлкәне алсаң да юклыкка терәлде. Әйтерсең лә, план белән дефицитка алып барылды. Хәлиткеч үзгәрешсез илнең яхшы якка борыласына өмет тә калмаган иде инде.

М. ГЫЙМРАНОВ,
сугыш һәм хезмәт ветераны.
Норлат шәһәре.

Кара, чагыштыр, нәтиҗә яса!

Район хуҗалыкларында уҗым культураларын чәчү һәм туңга сөрүнең барышы.

Мәгълүматлар 1991 елның 19 августына.

	Беренче багана—чәчелгән уҗым да), өченче—планга карата туңга сөрелгән җир, процентларда.		Икенче хуҗалыклар культуралары процентларда, дүртенче—бишенче—планга карата (гектарларда).	
Синдряков исем.	400	55	700	38
Ульянов исем.	500	64	890	41
«Правда»	150	21	530	27
«Восход»	390	65	752	45
Мичурин исем.	310	45	625	36
«Россия»	250	45	850	52
Хафизов исем.	480	65	870	57
«Путь к коммунизму»	406	39	580	27
Муса Җәлил исем.	260	40	550	47
«Родина»	200	36	370	32
«Игенче»	520	52	825	38
«Большевик»	320	53	615	40
«Заветы Ильича»	465	50	790	51
«Знамя Октября»	250	21	1050	67
«Алга»	870	54	930	29
«Комбайн»	790	53	1200	62
XXI партсъезд исем.	511	37	1883	56
«Татарстан»	540	51	710	51
«40 лет Победы»	330	51	620	38
«Чишмә»	350	42	360	18
«Таң»	380	62	810	67
«Москва»	260	37	630	37
«Үрнәк»	320	78	570	64
«Лесная Поляна»	48	37	55	17
«Кондырча»	250	59	270	40
Кузнецов исем.	220	32	510	35
«Заря»	300	46	650	55
«Чирмешән»	165	42	170	19
«Ленинский путь»	320	49	680	45
1 нче Май»	460	57	810	41
«Төрнәс» совхозы	248	22	802	38
«Мамык» совхозы	370	42	295	15
«Рассвет» совхозы	700	44	1816	65
«Сөлчә» совхозы	100	11	570	46
Хуҗалыкара берләшмә	80	32	435	46
«Яшь көч»	100	50	225	34
Район буенча	12563	45	24928	42

◇ Бер колхоз хәберләре

Ындыр табагы хуҗалары

«Таң» колхозы игенчеләре быелгы урып-җыюда да күтәренке кәеф белән эшләделәр. Ындыр табагында эш ике сменада барды. Төнге сменада эшләүче кызларны аеруча мактап үтәргә кирәк. Алар—Минзилә Сөнгатуллина, Әлфинә Мөхәммәдиева, Лилия һәм Нурсинә Сәйфуллиналар, Люция Кәримова, Руфия Әһлиуллина, Эльмира Сәгыйрова, Гөлүсә Миннеханова. Бу кызлар чакырганны да көтмичә көн саен ындыр табагына ашыгалар. Ашлыкны чистарту, киптерү, складларга кертүдә зур җаваплылык тоеп, сыйфатлы эшләре белән ярдәм иттеләр.

Ындыр табагының мөдире—Барый Вәлиәхмәтов. Ул үзе пенсионер. Аның аркасында биредә һәрчак тәртип, һәркем үзенең эш урынын, вакытын белеп тора. Шулай ук ике сменаны бер итеп эшләүче шоферлар турында да җылы сүзләр әйтәсе килә. Алар—колхозның үз шоферы. Тәлгать Хуҗәхмәтов һәм урып-җыю чорына «Сельхозэнерго»дан килгән Хәлил Сөнгатуллин. Ындыр табагындагы барлык эшләр дә алар хезмәтеннән башка үтәлми.

Хәзерлек бара

Хуҗалык кырларында салам җыю комплексы рәвештә бара. Урып-җыю вакытында тапаткан салам комбайннан ташылды. Бу эштә Радик Сәйфуллин, Җәүдәт Гыйбадуллин зур тырышлык күрсәттеләр.

Бүгенге көндә 1000 гектар чамасы җирдән салам җыелды. Тарттырылган салам үзвакытында эскертләргә куелып тора. Өючеләр Абдул Хатыйпов, Ринат Сәфәргалиев, Тәлгать Шәһиев һәм Рамил Селәйманов кышка хайваннарга азык хәзерләүдә көчләрен кызганмыйлар.

Р. ФӘХРЕТДИНОВ,
бригадир.

КИЛӘЧӘКНЕҢ ЯКТЫ ӨМЕТЛӘРЕ,

Татьяна Николаевна Маслова. Бу исем районыбыз педагогларына яхшы таныш. Татьяна Николаевнаның төрле киңәшмәләрдә, семинарларда ясаган акыллы киңәшләргә бай чыгышларын салмак, ягымлы тавышын, кояштай балкып торучы йөзен тиз генә оныту мөмкин түгел. Шулай да аны белмәүчеләрне дә бу педагог белән таныштырып үтәсе килә.

Т. Н. Маслова—шәһәрнең икенче урта мәктәбе директорының укыту эшләре буенча урынбасары. Хезмәттәшләре аның белән хаклы рәвештә горурланып, «Мәктәпнең йөрәге» дип атыйлар, чөнки биредә үткәрелгән һәр чараны ул башлап әйдәп йөри.

Татьяна Николаевна, гомумән, барлык педагогларның остазы. Үз мәктәп укытучылары гына түгел, районның башка укытучылары да аңа киңәш сорап еш киләләр, эш тәҗрибәсен өйрәнәләр.

Рәсемдә: СССР мәгарифе отличнигы Т. Н. Маслова.

Бер сорауга—бер җавап

Озак та үтмәс, мәктәпләр кыңгырау чыңына, балаларның шат авазларына күмелер. Бу көнне укучылар да, укытучылар да түземсезләнеп көтә. Уку елы ничек үтәр? Һәркемнең үз планы, үз максаты...

Шулар турында кызыксынып без бер төркем педагогия работникларына сораулар белән мөрәҗәгать иттек.

1. Химия-биология дәресләрендә балаларга экологик тәрбия бирү проблемасы ничек хәл ителә?

З. Д. ДАНИЛОВА—Андреевка урта мәктәбенең химия-биология укытучысы.

—Экономик тәрбияне—балаларга тәрбия бирү системасында иң мөһимнәрдән саныйм. Һәр елның мартында мәктәптә «Без һәм табигать» темасы буенча биология атналыгы үткәрүне үзенчәлекле бер традициягә әверелдереп җибәрүебез шуның ачык бер мисалы. Аның барышында без төрледән-төрле чаралар үткәрәбез. Балалар «Урман сукмагы» уенын бик яраталар. Пресс-конференцияләр, бүлмә гөлләре янына сәяхәтләр дә бик кызыклы үтә. Бу чараларны үткәрүдә «Яшь натуралист» түгәрәгенә йөрүче укучылар аеруча актив катнашалар.

Шунысын әйтергә кирәк, әлеге чаралар балалар тәрбияләүдә бик үтемле, аларда һәрвакыт зур кызыксыну уята. Һәм моның нәтиҗәсе дә күркәм. «Табигатьне иң яхшы белүчеләр» конкурсы барышында балаларның шулкадәр төгәл, уйланылган җавапларын үзе үк бер сөенеч. Табигатьне саклау буенча иң яхшы фәнни-фантастик проектка конкурс игълан ителгәч, укучылар ясаган рәсемнәр, алар төзегән проектларда өлкәннәрне дә хәйран калдырырлык, уйландырырлык фактлар күрсәтелгән иде. Әй тема, чыннан да, кызыклы иде: «Планетабыз өчмәченче елда» дип атала.

Моннан тыш химия дәресләрендә дә балаларга экологик тәрбия бирү өчен мөмкинлекләр чиксез дип саныйм. Сулый торган һавабызны сафландыру, эчә торган суыбызны чистарту, гомумән, табигатькә сак караш тәрбияләү балалар аңына яшьтән салынырга тиеш бит.

Саннар ни сөйли

1990—1991 елда район халык мәгарифе хезмәткәрләренең 62се санаторийларда, 12се ял йортларында сәламәтлекләрен нык ыттылар, 20 кеше «Ана һәм бала» санаторий-профилакторийларында ял итте, 10 кеше НУРБ профилакториенда дәваланды. Педагогия работникларының 160ы путевкалар буенча илебезнең төрле шәһәрләрендә туристлык сәяхәтләрендә булды.

х х х

Узган уку елында район мәктәпләренең меңгә якын укучысы яшь туристларның район станциясе линиясе буенча илебезнең төрле шәһәрләрендә туристик сәяхәтләрдә катнаштылар.

Җаваплы чор якынлаша

Район мәктәпләре яңа 1991—1992 уку елын яхшы хәзерлек белән каршыладылар. Барлык балалар учреждениеләре база хуҗалыклары ярдәме белән яхшы итеп ремонтланды. Шәһәрнең дүртенче, Бикуле, Югары Норлат, Фома, Андреевка мәктәпләренең хәзерлекләре аеруча яхшы.

Шунысы куанычлы, районның барлык балалары да диярлек типовой уңайлыклы мәктәпләрдә укый башлаячак. Якын арада Түбән Норлат авылында сафка керәчәк 192 урынга исәпләнгән мәктәп тә балалар, шулай ук педагогия коллективы өчен зур сөенеч булачак.

Гомумән, мәктәпләр балалар кабул итүгә бүгеннән әзер. Алар китап-дәреслекләр, уку-күргәзмә әсбаплары белән комплектланган, барлык мәктәпләрдә дә диярлек компьютер класслары, заманча җиһазландырылган уку кабинетлары бар. Боларның һәммәсе тулаем уку елын уңышлы башлап җибәрүдә мөһим алшарт булып тора.

Элеккеге еллардан аермалы буларак, районыбыз укытучылары менә инде икенче ел унбиш вариантлы уку планы нигезендә эшлиләр. Бу—укучыларга белем һәм тәрбия бирүнең нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итә, бөтен игътибарны ахыр нәтиҗәгә туплап эшләргә булыша. Мәктәп—укыту-тәрбия процессының үзәге. Шуңа да дәресләрнең нәтиҗәлелеген күтәрү, дәрес формаларын һәм ысулларын камилләштерү мәсьәләләре район халык мәгарифе бүлеге, шулай ук педагогия коллективларының игътибар үзәгендә. Һәр педагогик коллективта укытуны камилләштерүгә багышлап педагогик совет утырышлары, семинарлар үткәрү традициягә әверелде. Анда дәресләрнең сыйфатына әһәмият бирү, һәр укытучыны үз дәресен һәм башка укытучыларның дәресләрен тирәнтен анализларга тәкъдим итте. Бу—дәреснең төрен һәм формасын дөрес сайлавын, гомумән дәрес үткәрү осталыгын ачыклау өчен кирәк.

Шунысы игътибарга лаек, районыбыз педагоглары халык мәгарифе системасындагы һәр яңалыкны тотып алырга омтылалар, шул ук вакытта инде әлек тупланган бай тәҗрибәне онытып җибәреп, һәрчак эшне нульдән башларга ярамаганлытын яхшы аңлыйлар. Тәҗрибә күрсәткәнчә, укыту процессында төрле экспериментлар үткәрү дәрес формаларын камилләштерү укытучыларга укучылар белән эшләүдә оптималь метод һәм алымнар табарга ярдәм итә. Әнә шундый күпкырлы методик эш үткәрү нәтиҗәсендә укытучының педагогик осталыгы арта бара. Бу исә, үз чиратында, фәннәрне укытуның практик юнәлешле булуын тәэмин итәчәк, укытуның сыйфатын күтәрәчәк. Укытучылар дәресләрдә алдынгы тәҗрибәне мөмкин кадәр киңрәк кулланып, укытуны тормыш белән бәйләүгә ныграк игътибар итсеннәр иде.

Агымдагы елдан рус һәм башка милләт балаларына татар теле укыта башлау, шәһәребездә ихтыяҗга карап татар класслары ачу, балалар бакчаларында исә шундый группалар булдыру республикабызның суверенлыгы шартларында һәр милләт кешесенә дә татар телен өйрәнү өчен тулы мөмкинлекләр ача.

Бер үк вакытта мәктәп балаларында профессия белән кызыксыну, тырышып уку һәм хезмәттә катнашу ихтыяҗы тәрбияләү дә игътибар таләп итә. Бу катлаулы проблеманы хәл итү өчен һәр мәктәптә балалар интереслары буенча түгәрәкләр ачу кулдан килерлек нәрсә. Бу очракта мәктәпләргә пионерлар йорты, яшь туристлар станциясе дә ярдәм кулы сузарга тиеш. Хәер, бу юнәлештә дә безнең педагогларның тәҗрибәсе саллы инде.

Уку елы—җаваплы чор якынлаша. Аның һәр көнен нәтиҗәле, укучылар, шулай ук укытучылар өчен файдалы итеп үткәрү, һәр педагогтан үз эшенә намуслы караш, яшь буынга белем бирүдә армый-талмый эшләү таләп ителә.

Н. АБДУЛЛИН,
Октябрь район халык мәгарифе бүлеге мөдире.



Галина Алексеевна Ходячеваның мәктәп бусагасын аталап керүенә өч дистә елдан артык гомер узды. Коллективка күнегү, тәҗрибә туплау еллары күптән артта калды. Хәзер инде Галина Алексеевна шәһәрнең беренче урта мәктәбендә иң тәҗрибәле педагоглардан санала. Максаты бер—балаларга математика фәненнән төпле белем бирү. Шуңа да Галина Алексеевна чын мәгънәсендә һәр укучыга барып җитү, көчле укучылар һәм начар өлгерүчеләр белән индивидуаль эшләүгә зур игътибар бирә. Әнә моның җимешләре күркәм: Ходячеваның укучылары мәктәптә математика фәне буенча үткәрелгән төрле чараларда уңай нәтиҗә күрсәтәләр. Әй укытучы өчен моннан да зуррак шатлык булу мөмкинме соң?!

Галина Алексеевна—коллективның ихтирамлы кешесе. Ул мәктәпнең методик советы члены, агитатор. Укытучы-методист буларак та район педагоглары арасында абруе зур.

Рәсемдә: Г. А. Ходячева.

Бер сорауга—бер җавап

2. Агымдагы уку елында тарих укытучыларына эшне ничек оештырырга тәкъдим итәр идегез?

З. Г. АПЫШКОВА—шәһәрнең беренче урта мәктәбенең тарих укытучысы.

—Җәмгыятебезнең хәзерге этаптагы үсеше халык мәгарифе системасы алдына күптөрле бурычлар куйды. Аларны хәл итү укучыларны табигать, кеше, җәмгыять турында план системасы белән коралландыруга бәйле. «Кеше һәм җәмгыять» курсын кертү җәмгыять дисциплиналары буенча белем бирүне үзгәртеп коруның нигезе булып торырга тиеш. Бу өлкән класс укучыларына хәзерге дөньяда кеше проблемалары буенча башлангыч җәмгыять хәзерлеге бирергә булышты. Әлеге курс кеше һәм җәмгыять турында ачык һәм кызык итеп сөйләячәк, хәзерге катлаулы дөньяда егетләр һәм кызларның үзбилгеләнүләренә ярдәм итү өчен мөмкинлекләр бирәчәк.

Мәктәпләр укытучыларына укучылар контингентының региональ специфика һәм милли-культура үзенчәлеген искә алып үзләре өчен курсның иң кулай вариантын сайлау мөмкинлеге ачылачак. Бу укытучының иҗади потенциалын ачарга, укучылар хәзерләү сыйфаты өчен аның җаваплылыгын күтәрергә ярдәм итәчәк. Укытучы кайсы программаны сайлар, яки кулай күрер? Минем уйлавымча, яшьләрнең дөньяны танып белү буенча белемен активлаштыру, аның социаль өлгергәнлеген тизләтүне үзенең төп бурычы итеп куйсын ул. Хәер, икенчесе— укучыларның шәхес буларак формалашуы, күнел культурасының үсүенә шартлар тудыручысы да икенчел нәрсә түгел. Ә бәлки безнең эраның өч мененче елның цивилизацияләнгән үсеше шартларында тормышка хәзерләүдә дөньяны танып белү һәм гомуми культура хәзерлеген алга куючысын сайларгадыр?

Программаны сайлау—укытучының үз эше. Вакыт дөньякүләм стандартларга җавап бирүче гуманитар белем бирүнең яңа сыйфатына күчүне таләп итә бит.

ЯҢА ПРЕМИЯ

ТССР Халык мәгарифе министрлыгы һәм РСФСР Педагогия җәмгыятенең Татарстан бүлеге Президиумы карары белән Каюм Насыйри исемендәге премия булдырылды.

Ул республикада халык мәгарифен үстерүгә аеруча зур өлеш керткән укытучыларга, фәнни хезмәткәрләргә бирелә. Лауреатлар исеме ел саен Укытучылар көнендә игълан ителә.

ЯЗМЫШЛАРЫ СЕЗНЕҢ КУЛЛАРДА

Игътибар: яңалык

Быел район халык мәгарифе системасында яңа белгечлек кертелде. Ул —мәктәп психологы. Сүзне яңа белгеч—Маргарита Алексеевна ИШМУЛИНАга бирәбез.

—Бүгенге көндә балаларны беренче класска психологик сайланыш нигезендә алу зур әһәмияткә ия. 6 яшьләкләрдә укучы булырга омтылыш зур була. Әгәр укырга-язарга өйрәтү шушы чорда башланмыйча, соңга калса, киләчәктә белемне үзләштерү кыенга киләчәк. Бу чорда педагогик тәэсир итү балаларның психик үсешен билгеләүче фактор булып тора.

Балаларның күпчелеге мәктәпкә бакчадан килә һәм шунда алты яшьтән 1 нче класста укый башлаган була. Аларның мәктәптә укырга ни дәрәҗәдә әзерлекле булуын ачыклау өчен мин алты яшьләкләргә күзәтү үткәрдем. Нәтиҗәләрдән күренгәнчә, группаларда балаларның күпчелеге урта һәм түбән хәзерлектә. Мондый балалар белән ата-аналар да, тәрбиячеләр дә өстәмә эш алып барырга тиешләр. Әйтергә кирәк, элегә мәктәп тәрбиячесе Н. А. Савинова бу сыйфатларның барысына ия.

Рәсемдә: тәрбияче Н. А. Савинова.

Ярдәмче интернат-мәктәптә тәрбияче эше җиңеллә рдән түгел. Балалар зур игътибар таләп итә. Шуна да биредә тәрбияләнүчеләр төпле белем алсыннар, җәмгыятебезгә яхшы кешеләр булып үссеннәр дисәң, ай-һай зур көч куярга, түземле булырга һәм иң мөһиме, намуслы эшләргә кирәк. Әлеге мәктәп тәрбиячесе Н. А. Савинова бу сыйфатларның барысына ия.

Кызганычка каршы, безнең илдә мәктәп программаларының саны җитәрлек түгел. Ә мәктәпкәчә учреждениеләр өчен әйтеп тә торасы юк. Гадәти мәктәптә сәләтле балалар да, нормаль үсештәгеләр дә һәм үсешендә бераз тоткарлыклар булганнары да, дөлай ук хәтта нәселдән-нәсел авыруы булган һәм кечкенә чакта көчле сырхау кичергәннәр дә бер үк класста укыйлар. Алар белән аерым-аерым шөгыльләнергә кирәк.

Алты яшьләкләр белән эшләгәндә укытучы өчен төп кыенлык —балаларның мәктәп чынбарлыгын бик төрлечә кабул итүләре. Бер үк дәрес берәүләре өчен уку, белем алу, икенчеләре өчен уен, аралашу буларак кабул ителә. Күбрәк хәзерлекле балалар өчен эмоциональ ярдәм, хуплаулы караш та җитә. Алар мәктәпкә әзерләнгәндә ата-ана ярдәмен дә кирәксенмиләр, кирәк әйберләрен портфельгә үзләре тутыралар, үзләре киенәләр һәм башкалар. Алар өчен укытучы—зур авторитет.

Кыскасы, балаларның укуга булган сәләтен бакчада чакта ук ачыклау, белем алуга, мәктәпкә омтылыш формалаштыру бик мөһим. Һәм классларны да үсеш дәрәҗәсе буенча төркемләү кирәк. Чөнки бердәй хәзерлекле балаларның бергә шөгыльләнүе аларның үсеше өчен кулай шарт икәнлеге эксперименталь рәвештә расланган нәтиҗә.

Бер сорауга—бер җавап

3. Район мәктәпләрен дәреслекләр белән тәэмин итүне канәгатьләнерлек дип саныйсызмы?

Р. И. САДРЕТДИНОВА —район халык мәгарифе бүлеге методисты.

—Бу турыда сөйләүне мәктәпләрне реорганизацияләүдән башласам әйбәтрәк булыр. 1989—1990 уку елыннан алып бүгенгәчә райондагы тулы булмаган 10 урта мәктәп урта мәктәп итеп үзгәртелде. Аңлашыла ки, учреждениеләрнең 10—11 нче класс укучыларын дәреслекләр белән комплектлаштыру мәктәпләр алдына иң беренче бурыч булып килеп баса. Моның өчен китапларны аларга башка мәктәпләрдән күчерергә кирәк. Әйтергә кирәк, әлегәчә реорганизацияләнгән теге яки бу мәктәпнең дәреслекләр җитмәүдән иза чиккәннәре булмады. Башка мәктәпләр алдында андый проблема туганы юк. Узган уку елында гына да 24212 сумлык дәреслек, 4,5 мең сумлык методик кулланма сатып алынды. Соңгысы район мәгарифе бүлегенең методик кабинеты исәбеннән мәктәпләргә бушлай таратылды.

Шунысын да әйтергә кирәк, чуваш авылларындагы рус мәктәпләрендә балаларга чуваш теле укытыла. Әмма аларның базалары ярлы. Әлеге хәлдән чыгу максатында бүлек хезмәткәрләре махсус рәвештә автобуслар белән Чабаксар шәһәренә баралар. Моның нәтиҗәсе дә саллы. Ел саен аннан 1,5—2 мең сумлык чуваш телендәге дәреслекләр, әдәби һәм методик әдәбият алып кайтабыз. Бер үк вакытта мәктәпләр Норлаттагы китап кибете аркылы да китаплар белән комплектлана. Үзебез дә башкаларга ярдәм итәбез. Менә инде ике ел рәттән үзебезнең мәктәпләрдән артып калган татар теле дәреслекләрен Яр Чаллыдагы татар гимназиясенә озатабыз.

Билгеле инде, мәктәпләрне китап-дәреслекләр белән тәэмин итүдә проблемалар да юк түгел. Аларны хәл итү өстендә һәрдаим эшлибез. Әле менә агымдагы елның беренче яртыеллыгында 16 мең 500 сумлык дәреслек кайтарттык. 1991—1992 уку елында 10 мең сумга методик әдәбият сатып алуны планлаштырабыз.

Санар ни сөйли

Былтыр яшь туристларның район станциясе каршында 39, район Пионерлар йортында 23 түгәрәк эшләде.

Бер сорауга—бер җавап

4. Базар мөнәсәбәтләренә күчү уңае белән, белемле булуның да дәрәҗәсе күтәреләчәк. Икътисади шартларның начарлануы сәбәпле урта мәктәпләрнең өлкән классларыннан китүче яшьләр дә артырга мөмкин. Шуңа да кичке һәм читтән торып укыту мәктәпләре эшен ныклы җанландыру кирәклегенең мөһимлеге тагын да артадыр инде?

Е. В. БОРИСОВА— район кичке һәм читтән торып уку мәктәбе директоры.

—Әйе, арта. Кичке мәктәптә укытуның эчтәлеген һәм формаларын тиз арада яңарту таләп ителә. Бу табигый, чөнки соңгы елда бездә укучылар контингенты яшәрде. Әгәр дә элегрәк аларның күпчелеге 35 яшьтән олырак булса, соңгы елларда укучыларның 80 проценты—14—20 яшьлек егет һәм кызлар. Ә бу яшьтәгеләр катлаулы, тәрбиягә, белем бирүгә авыр бирешүчән. Мондый очракта безгә теге яки бу укучыбыз эшли торган предприятие, оешма ярдәм кулын сузарга тиеш. Кызганычка каршы, элегәчә мондый булышлык тойганыбыз юк.

Кичке мәктәп —өлкәннәр мәктәбе. Димәк, җиһазларның, техник средстволарның көндезге мәктәптәгегә караганда күпкә югары дәрәҗәдә булуы шарт. Ә элегәчә физика, химия һәм информатика нигезләреннән белем, кем әйтмешли, бармаклар ярдәмендә генә бирелә. Мәктәпкә бүленә торган акча средстволары елдан-ел кимегәндә белем бирүнең югары дәрәҗәсе турында хыялланырга гына кала.

Еш кына кичке мәктәпнең белем турында документ алу өчен генә булуы, аның ныклы белем бирмәве турыда ялгыш фикер ишетергә туры килә. Уйлап карагыз, безгә яшьләр белем алуның мөһимлеген, зарурилыгын аңлаган яшьтә, киләчәктә дә укуларын дәвам итү теләге белән киләләр бит. Ел саен бездән 30 кеше урта белем турында документ алып чыгып, шуларның 30 процент укуларын училищеларда, техникумнарда дәвам итә икән, бу безнең өчен зур шатлык.

5. Соңгы вакытта пионериягә игътибар кимеде. Ә менә сездә алар белән эшләүгә әһәмият арта бара сыман. Бу, чыннан да шулаймы?

Г. Д. ӘҺЛИУЛЛИНА— Пионерлар йорты директоры.

—Әйе, нәкъ шулай. Быелгы елга планнар турында сөйләгәнче узган уку елы нәтиҗәләрен искә алмый мөмкин түгел. Былтыр безнең районның 4—7 класс укучылары үз теләкләре белән Татарстан пионерварислары союзына керделәр. Ә элеге оешманың максатлары изге: союзның һәр членын кызыклы тормыш белән яшәргә, көчле, акыллы, намуслы булырга өйрәтү.

Узган ел союз өчен берләшү, күмәкләшү елы булды. Безнең Пионерлар йортында өлкән пионервожатыйлар, мәктәпләр активистлары очрашып киңәштеләр.

Быел эшне тагын да җанландыруны максат иттек. Аерым алганда мәктәпләрдә очрашулар, пионер лидерлары һәм мәктәп активының күчмә семинарын оештыру күздә тотыла. Балаларның теге яки бу шөгыльгә кызыксынуын арттыру өчен бөтен коллектив белән авыл мәктәпләренә «чыгу»ны оештырачакбыз. Уйлавымча, балаларны бергә, музыкаль инструментларда уйнарга, газета чыгарырга өйрәтү буенча максатка юнәлешле эш башларга алынырбыз. Шәһәр мәктәпләре укучыларын да кызыклы шөгыльләр, мавыктыргыч эшләр көтә. Быел бездә яшь натуралистлар, пианинода уйнарга, художестволы җиһазлауга өйрәтүче яңа түгәрәкләр ачылачак. Моннан тыш, быел Пионерлар йортында «Аленушка» ательесы эшли башлаячак.

Һәрвакыт әзер

Безнең шәһәрдә республика фильмотекасының район бүлеге бар. Анда мәктәптә укытыла торган барлык фәннәр буенча фильмокопияләрнең бай фонды туплангган.

Соңгы елларда күп мәктәпләрдә укытуның кабинет системасы кертелде. Бу исә, үз чиратында, техник чаралар, шул исәптән тавышлы кинодан файдалану өчен дә кин мөмкинлекләр тудырды. Тавышлы кино—дәрес өчен бик тәэсирле, үтемле ярдәмлек ул.

1990—91 елларда безнең фильмотека үзенең эшен мәктәпләрне укыту фильмнары белән нәтиҗәле тәэмин итүгә юнәлдерде. Мамык, Төрнәс, Чулпан, Иске Чаллы, Бикуле, Егоркино һәм Якушкино урта мәктәпләре укытучылары әлеге фильмнарны үз дәресләрендә күп файдаланалар.

Дәресләрдә техник чараларны файдалану өчен техник кадрларны хәзерләми генә булмый. Шуна күрә, ел дәвамында фильмотекада кино күрсәтүчеләрне хәзерләү буенча курслар оештырабыз.

Укытучылар хезмәте нәтиҗәле булсын өчен без ярдәмгә һәрвакыт әзер.

Л. ЗЮЗЛЯЕВА,

Ольга Максимовна Игнатьева Пионерлар йортында 10 елга якын эшли. Тегү түгәрәгән җитәкли ул. Ел саен түгәрәктә 100 дән артык кызның тегү эшенә өйрәнүен искә алсак, узган гомердә күпме яшүсмердә хатын-кыз өчен иң мөһим бу шөгыльгә мәхәббәт уяткан лыгын санап чыгару кыен булмас. Быел Ольга Максимовна аеруча күтәренке күңел белән эшли. Чөнки дистә елдан артык тегү кабинетында балалар искергән берничә тегү машинасы белән эшләргә мәҗбүрләр иде. Ә менә узган ел кабинет 15 данә яңа заманча машина исәбенә яңарды. Шулай булгач, әлеге түгәрәк базасында хуҗалык исәпле тегү цехы ачу да кулдан килмәслек нәрсә түгел.

Ольга Максимовна коллективта хезмәт сөючәнлеге, һәркемгә ярдәмгә килергә әзер торуы, намуслы булуы белән аерылып тора.



Рәсемдә: О. М. Игнатьева.

ТЕЛЕВИДЕНИЕ

СИШӘМБЕ
20 АВГУСТ
ҚАЗАН ҮРСӘТӘ

17.10 Татарстан Республикасы көненә карата телевизион фильмнар фестивале. «Моабит дәфтәре».
18.35 «Редакциягә хат килде».
19.00 «Татарстан».
19.30 «Нур балкысын өйләрдә...». Безнең чыгышлар әзеннән.
20.00 Әлли-бәлли-бәү.
20.10 Авыл хезмәтчәннәре өчен концерт.

I ПРОГРАММА

6.30 «Иртә».
9.00 «Салкын йорт». Нәфис фильм. 1 серия.
9.55 Киноконцерт.
10.45 Халык моңнары.
11.00 Балалар сәгате.
12.00 «ТЯХ».
12.15 Актуаль репортаж.
12.30 Фильм-концерт.
15.00 «ТЯХ».
15.15 «Һөнәре—тикшерүче». Нәфис фильм. 1 серия.
16.20 Һәвәсләр дөньясы.
16.35 Музыкаль программа.
17.55 Балалар өчен кыска метражлы нәфис фильмнар.
18.20 Концерт.
18.30 «ТЯХ».
18.45 «Тулган ай яктысындагы әңгәмәләр».
19.30 Мультфильм.
19.45 Николай Цукин жырлый.
20.05 «Салкын йорт». Нәфис фильм. 1 серия.
21.00 «Вакыт».
21.40 Баскычлар.

II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.20 Мультфильм.
8.40 Ритмлы гимнастика.
9.10 Концерт.
9.50 Мультфильм.
10.25 «Башка эшкә күчү сәбәпле». Нәфис фильм. 1 серия.
11.30 «Сергей Абрамчук: майор була алмаган капитан».
12.15 Документаль фильм.
12.45 «Анламыйм...». М. Задорнов һәм С. Альтов катнашында филым.
13.20 «Гитлерга соната». А. Сокуров фильмы.
13.30 Балалар өчен фильм.
14.50 «Образ».
21.40 Ватандашлар Халыкара конгрессында.
22.00 «Бишенче тәгәрмәч».

ЧӘРШӘМБЕ
21 АВГУСТ
ҚАЗАН ҮРСӘТӘ

18.05 «Осталыкка һәм матурлыкка юл». СПТУ-36.
18.15 «Очрашулар». Шагыйрь Гәрәй Рәхим.
19.00 «Татарстан».
19.30 «Туры элемтә». Тамашачыларның сорауларына ТССР Халык мәгарифе министрлыгы җитәкчеләре җавап бирә.
20.30 Әлли-бәлли-бәү.
20.35 Л. Әхмәтова жырлый.

I ПРОГРАММА

6.30 «Иртә».
9.00, 20.05, 03.00 «Салкын йорт». Нәфис фильм. 2 серия.
9.55 Сез моны булдыра аласыз.
10.40 Мультфильм.
11.00 Чемпионнар белән бергә.
11.15 Балалар музыка клубы.
12.00 «ТЯХ».
12.15 Актуаль репортаж».
12.30 Н. Лесков. «Талау».
15.00 «ТЯХ».
15.05 «Һөнәре—тикшерүче». 2 серия.
16.25 Һәвәсләр дөньясы.
16.40 Тисагати биюләре (Венгрия).
17.00 Документаль фильм.
17.30 «Аяк астында чуалма». Нәфис фильм.
18.30 «ТЯХ».
18.45 Планета.
19.30 Хәтер һәм хакыйкать бурычы.
20.00 Шигърият минутлары.
21.00 «Вакыт».
21.40 Вакытлы нәрсәләр һәм мәңгелек турында.
22.40 Концерт.
23.45 «ТЯХ».
00.05 Спортның су төрләре буенча Европа чемпионаты.

II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.20 Концерт.
8.50 «Адам Смитның акча дөньясы».
9.30 Мультфильм.
10.15 «Көнчыгыш Себер». Киножурнал.
10.25 «Башка эшкә күчү сәбәпле». Нәфис фильм. 2 серия.
11.30 «Борис Покровский Моцартның «Дон Жуан» операсын куя».
13.10 «Бию театры».
13.30 Балалар өчен фильм.
14.35 «Титаннар образы».
21.40 «Түбә». Нәфис фильм. (Италия).
23.30 «Хәбәрләр».

ПӘНҖЕШӘМБЕ
22 АВГУСТ
ҚАЗАН ҮРСӘТӘ

17.05 Балалар өчен. «Урмандагы тамаша». Телеспектакль.
18.10 «Табигать һәм кеше».
19.00 «Татарстан».
19.30 «ЭКО» студиясе.
20.00 Әлли-бәлли-бәү.
20.10 «Эшләр һәм кешеләр». Түбән Кама районының «Красный Ключ» кошчылык фабрикасы.

I ПРОГРАММА

6.30 «Иртә».
9.00, 20.05, 02.40 «Салкын йорт». 3 серия.
9.55 Документаль фильм.
10.30 Мультфильмнар.
11.00 Балалар сәгате.
12.00 «ТЯХ».
12.15 МВД хәбәрләре буенча.
12.30 Фильм-концерт.
15.00 «ТЯХ».
15.15 «Һөнәре—тикшерүче». 3 серия.
16.25 Фильм-концерт.
17.25 Документаль фильм.
18.00 «Тамбу Ламбу». Балалар өчен фильм.
18.30 «ТЯХ».
18.45 «...16 яшькә кадәр һәм өлкәнрәкләр өчен».
19.30 «Келу» ансамбле чыгышы (Саранск).
19.40 Дипломатик булмаган әңгәмәләр.
21.00 «Вакыт».
21.40 МВД хәбәрләре буенча.
21.55 Камера дөньяга карый.
22.55 «Пи» билгесе астында.
00.40 Спортның су төрләре буенча Европа чемпионаты.
01.25 Сезне Лев Лещенко чакыра.

II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.20 Концерт.
8.50 Ритмлы гимнастика.
9.50 Мультфильм.
10.10 «Туганнар арасында кечкенәсе». Нәфис фильм. 1 серия.
11.30 Документаль фильм.
12.50 «Йа-хха». В. Цой катнашында документаль фильм.
13.30 Балалар өчен фильм.
14.35 «Импрессионистлык».
21.40 Ватандашлар Халыкара конгрессында.
21.55 «Суда—музыка».
22.55 Реклама.
23.00 «Хәбәрләр».
23.15 «Кешеләр, без барыбыз да замандашлар».

ҖОМГА
23 АВГУСТ
ҚАЗАН ҮРСӘТӘ

17.10 Татарстан Республикасы көненә карата телевизион фильмнар фестивале. «Галимҗан Ибраһимов», «Бакый Урманче», «Бу театр бит», «Җыр бүләк итәм».
18.10 «Палитра». «Зур Идел» күргәзмәсе йомгаклары.
19.00 «Татарстан».
19.30 Татарстан Республикасының Дәүләт гербы һәм флагы.
19.50 Әлли-бәлли-бәү.
20.00 «Җомга көн кич белән». Альманах.
20.55 Тапшырулар программасы.

I ПРОГРАММА

6.30 «Иртә».
9.00, 20.00, 02.30 «Салкын йорт». 4 серия.
9.55 «...16 яшькә кадәр һәм өлкәнрәкләр өчен».
10.40 Мультфильм.
10.50 Документаль фильм.
11.20 Лирик концерт.
11.40 «ТЯХ».
11.55 Җиңел атлетика буенча дөнья чемпионатын ачу. Японнардан тапшыру.
15.00 «ТЯХ».
15.15 «Һөнәре—тикшерүче». 4 серия.
21.40 МВД хәбәрләре буенча.
22.00 «ВиД» күрсәтә.
00.50 Анарда ниндидер тылсымлы ут яна.
01.20 Ганна Главари.

II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.20 «Тере планета». 12 серия.
9.15 «Рус триосы» чыгышы.
9.35 Мультфильм.
10.15 «Туганнар арасында кечкенәсе». 2 серия.
11.30 Документаль фильм.
12.25 Концерт.
12.50 «Буклет».
13.20 Мультфильм.
13.30 Балалар өчен фильм.
14.35 «Актерлар биржасы-91».
21.40 «Коллаж».
21.45 Өлкәннәр өчен мультфильмнар.
22.00 «Бишенче тәгәрмәч».

ШИМБӘ
24 АВГУСТ
ҚАЗАН ҮРСӘТӘ

17.15 «Телевизорыгызны сүндерергә, онытматыз». Нәфис фильм (татар телендә).
16.30 ТССР Дәүләт жыр һәм бию ансамбле чыгышы.
19.00 «Татарстан».
19.30 Концертның дәвамы.
20.30 Әлли-бәлли-бәү.
20.40 «Шигърият». Салисә Гәрәева.
20.55 Тапшырулар программасы.

I ПРОГРАММА

6.30 Тынлы оркестр уйный.
6.45 Мультфильмнар.
7.30 Ритмлы гимнастика.
8.00 Иртәнге көнне ачу программасы.
8.30 «ТЯХ».
8.45 Әти, әни һәм мин.
9.15 А. Н. Островский. «Коллар» фильм-спектакле.
11.50 Таң йолдызы.
12.50 Имин хәрәкәт.
13.20 Концерт.
13.55 «Нокиның мультсәяхәте». Киноконцерт.
14.40 Концерт.
15.00 «ТЯХ».
15.15 Документаль-публицистик фильм: «РС-00» һәм башкалар».
16.15 «Җыр-91».
17.20 Документаль фильм.
17.30 Мультфильм.
17.55 Халыкара панорама.
18.40 Режиссер М. Захаров фильмнары. «Свифт төзегән йорт». 1 һәм 2 серия.
21.00 «Вакыт».
21.40 «XX гасыр солдатлары сугышка каршы» дигән халыкара телемарафонга карата.

II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 «Сәламәтлек».
8.45 «Спорт һәркем өчен».
9.00 Мультфильмнар.
9.30 «Дуслык» видеоканалы.
13.30 Тамашачыларның сорауларына РСФСР Министрлар Советы Рәисе И. Силаев җавап бирә.
14.00 «Гаилә» телепрограммасы.
15.00 Фәнни-популяр фильм.
15.30 Җиңел атлетика. Дөнья чемпионаты.
17.00 Ватандашлар. Халыкара конгрессында.
21.40 Спорт программасы.
23.00 «Хәбәрләр».
23.15 Кинокомедия.

Кизләү авылында яшәүче кадерле әтиебез Исламнур Сәгыйрь улы Кәримовның тууына 60 яшь тула.

Юбилеең белән, әти, сине
Чын күңелдән кайнар котлыйбыз.
Әни белән тигез, рәхәт итеп
100 яшькәчә гомер итегез.

УЛЛАРЫ, ҚЫЗЛАРЫ, ҚИЯҮЛӘРЕ, ҚИЛЕННӘРЕ, ОНЫҚЛАРЫ.

x x x

Яңа Иглай авылында яшәүче әтиебез Салих Шакир улы һәм әниебез Зәмзәмия Әһлетдин кызы Насыйровларга быел 50 яшь тулды. Аларның шат, сәламәт булып озак яшәүләрен, тигез гомер итүләрен телибез.

Гомерегезнең бу бәхетле көне
Күңелегездә калсын уелып.
Тәбриклибез сезне чын күңелдән,
Барыбыз да бергә жыелып.

ҚЫЗЛАРЫ, УЛЛАРЫ, ҚИЯҮЛӘРЕ, ОНЫҚЛАРЫ.

28 июльгә каршы төндә Синдряков исемендәге колхозның дуңгызчылык комплексыннан «Рекорд» телевизоры урланды.

31 июльдә Урта Чаллы клубының 2 магнитофонын урладылар. Тикшерү алып барыла.

4 августка каршы төндә 53 нче СМУның ашханәсеннән акча урлануы хакында хәбәр алынды.

20 көн эчендә җәмәгать урыннарында һәм көнкүрештә 50дән артык вак хулиганлык очрагы теркәлде. Бу саннарга карап, без милиция хезмәткәрләре, җәмгыятькә һәм шәхескә каршы авыр жинаятьләрнең шактые үз вакытында тоткарланды һәм кисәтелде дип әйтә алабыз. Әмма явыз хулиганлык очраклары да юк түгел. Мәсәлән, 2 августта Кормышта яшәүче Куликов исерек хәлендә үзенең өйдәше Р. Моратованы кыйнаган.

5 августта Норлаттан Игътисамова ире кыйнаганлык хакында милициягә мөрәҗәгать итте.

Шушы 20 көндә барысы төрле характердагы 42 жинаять очрагы теркәлде. 99 кеше эчкән килеш җәмәгать урыннарында йөргән өчен, 58 кеше вак хулиганлык өчен жаваплылыкка тартылды.

ТАБЫЛДЫҚЛАР ӨСТӘЛЕ

Түбән Норлат авылында инде 3 атна бер яшьләр чамасындагы кызыл бозау яши. Сул колагында тамгасы бар. Тимербулатов Минеголга мөрәҗәгать итегез.

БЕЛДЕРҮЛӘР

ЦБПО РЭПО энергетик жиһазларын ремонтлау буенча Әлмәт үзәк базасының Норлат цехына эшкә электротехник жиһазларга хезмәт күрсәтү өчен 3—4 разрядлы электр монтерлары (эш хакы 510—700 сум), 3—4 разрядлы ремонтчы-слесарьлар (510—700 сум) кирәк.

Норлат цехы «Норлатнефть» НГДУсының производство хезмәте күрсәтү базасы территориясендә урнашкан. Телефон: 1—18, «Кормыш» автобус тукталышына кадәр барырга.

x x x

«Дуслык» газетасы редакциясенә даими эшкә корреспондент, хужалык мәдире кирәк. Белешмәләр өчен газета редакторына мөрәҗәгать итәргә.

Район үзәк шифаханәсе коллективы улы **РИНАТ**ның фажигале рәвештә вафат булуы сәбәпле Чулпан участок шифаханәсе балалар табибе Д. В. Мотыйгуллинаның авыр кайгысын уртаклаша.

МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.

Учредительләр халык депутатларының Октябрь район Советы, КПССның партия комитеты.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, жаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА жыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор Зөлфия ВӘЛИЕВА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьнең 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак. Заказ 100. Тираж 3415.